**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Тымытык авыл җирлеге Советы**
**Карары**

Тымытык авылы №20-35 «12»август 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 ноябрендә 62-45 номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 12 октябрендә 67-102 номерлы карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 мартындагы 170 номерлы «Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык карамагындагы хокук, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге 976 нчы номерлы карары белән расланган,кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында карары нигезендә

Тымытык авыл җирлеге советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 ноябрендә 62-45 номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыц «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген

(җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибенә (2018 елның 12 октябрендә 67-102 номерлы карар редакцниясендә) 5.2 нче пунктны түбәндәге редакцниядә түбәнедәге бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«5.2. Әлеге Тәртипнең 1.6 пунктында каралган шартларда төзелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә милекне арендатор тарафыннан аренда шартнамәсе буенча йөкләмәләрне үтәмәүгә бәйле яисә, әгәр арендатор әлеге Тәртипнең 1.6 пунктында каралган критерийларга туры килмәсә, дәүләт милкеннән фактта файдалануның бөтен срогы аренда бәясеннән аны төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча шартнамәдә билгеләнгән 100 процент күләмендә түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Тымытык җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә

Рәис Э.Х. Гыйләҗева